**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 14-40 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 40-3 номерлы «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе” муниципаль казна учреждениесе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә идарә функцияләрен башкару өлкәсендәге вәкаләтләрне камилләштерү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 40-3 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (Казан шәһәре Думасының 2012 елның 7 июнендәге 15-14 номерлы, 2014 елның 3 мартындагы 19-31 номерлы, 2014 елның 29 маендагы 14-33 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 17-36 номерлы, 2014 елның 27 ноябрендәге 8-39 номерлы, 2015 елның 4 мартындагы 13-41 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге 19-43 номерлы, 2015 елның 3 августындагы 23-44 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 24-2 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 13-3 номерлы, 2016 елның 16 сентябрендәге 11-10 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 25-13 номерлы, 2018 елның 24 гыйнварындагы 7-23 номерлы, 2018 елның 29 октябрендәге 16-29 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 9-30 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге 13-32 номерлы, 2019 елның 20 июнендәге 13-34 номерлы, 2020 елның 15 маендагы 15-39 номерлы, 2022 елның 15 апрелендәге 12-13 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 9-19 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1.21 пунктта «өстәмә белем бирү» сүзләреннән соң «балаларның» сүзен өстәргә;

1.2. 3.1.27 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.27. гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә аз керемлеләр дип тануны гамәлгә ашырырга. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннарга мохтаҗ дип танылган гражданнарның исәбен алырга, исәптән төшерергә, исәпкә алу эшләрен формалаштырырга»;

1.3. 3.1.43 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.43. үз компетенциясе чикләрендә (шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты исеменнән) гражданнарны торак урыннардан чыгару эшләре буенча суд бәхәсләрен карауда, коммуналь түләүләрне яңадан санауда, торак биналарга һәм рөхсәтсез корылмаларга милек хокукын, җир һәм башка бәхәсләрне тануда катнашырга»;

1.4. 3.1.44 пунктны төшереп калдырырга;

1.5. 3.1.68 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.6. 3.1.84 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.84. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруда, шул исәптән үз компетенциясе чикләрендә юл хәрәкәте мониторингында катнашырга»;

1.7. түбәндәге эчтәлекле 3.1.96 пунктын өстәргә:

«3.1.96. 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны башкарырга»;

1.8. 3.1.96 пунктын 3.1.97 пункты дип санарга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясенә (Р.Р.Фәтхетдинов) әлеге карар буенча Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны, дәүләт тарафыннан теркәгәннән соң, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**